**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 май № 306

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче; 2015 ел, 3 июль, 483 нче, 2015 ел, 22 август, 612 нче, 2015 ел, 30 декабрь,1033 нче, 2016 ел, 09 март, 132 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә түбәндәге үзгәрешлщрне кертергә:

6 пунктның таблицасында:

8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «8. | ИК, ҖТКИ | Гамәлдә күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр, антенна хезмәтләре өчен түләүләр турында мәгълүматларны исәпләү һәм тапшыру, персональләштерелгән социаль счетлар күзлегеннән караганда коммуналь хезмәтләр куллану нормативлары, гражданнар тарафыннан 2 айга, шулай ук тоташтан 3 ай һәм артыграк чорда торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен агымдагы түләүләрне түләмәү факты турында, җыелган бурычлары түли башлау факты хакында яки аны түләү буенча килешү төзү һәм (яки) аны үти башлау хакында, коммуналь хезмәтләрне өзү факты, коммуналь хезмәтләрне тоташтыру факты турында мәгълүматларны исәпләү һәм тапшыру | электрон | хисап аеннан соң килүче айның 3сенә кадәр | МПРҮ бүлекләре»; |

29 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «29. | ТР ХЭБТИhСЯМ | Җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләр арасыннан балага айлык пособие билгеләнгән, 4 – 17 яшьлек балалар турында мәгълүматлар | электрон | хисап аеның 20 сенә кадәр | ТР ССМ, ТР ЯШhСМ, МИБ»; |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков